**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**2018 елның 30 ноябре № 102 Олы Мишә**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мишә авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында"гы 2014 елның 26 ноябрь аендагы 147 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге, "Россия Федерациясе Салым кодексы 52 нче статьясенең беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында"гы 2018елның 03 августындагы 334-ФЗ санлы Федераль законга туры китереп, Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар кабул итте,

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында"гы 2014 елның 27 ноябрь аендагы 124 нче санлы 2014 елның 26 ноябре № 147 (2015 елның 20 мае № 180 санлы, 2015 елның 12 октябре № 7 санлы, 2018 елның 12 апреле № 82 санлы редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлектәге 3.2 пункты өстәргә:

"3.2. Түбәндәге физик затларны милек салымыннан азат итәргә:

3.2.1. 18 яшькә кадәрле дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булганнарны;

3.2.2 әлеге пунктның 3.2.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын;

3.2.3. тулы дәүләт тәэминатында булмаган инвалид балаларның ата-аналарын

(уллыкка/кызлыкка алучылар, опекуннар, тәрбиягә алучылар).

Салымга ташламалар түбәндәге объектларга каралган:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салымга ташлама, салым түләүченең теләге буенча, гаилә карамагындагы бер генә объектка бирелә.

Салымга ташлама Олы Мишә авыл жирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге максатларында кулланылмаучы объект өчен тиешле салым күләмендә бирелә.

Салымга ташламага хокукы булган физик затлар салым органына салымга ташлама бирү турында гариза яза, шулай ук салым түләүченең салымга ташламага хокукын раслаучы документлар тапшыра ала.

Салымга ташламага хокукны раслаучы документлар булып әлеге төр салым түләүче физик затның шәхесен раслаучы документ, шулай ук аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яки өч һәм аннан да күбрәк балаларның туу турындагы таныклыклары тора.

Салымга ташламалы объектны сайлавы турында салым түләүче салым органына салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр хәбәр итәргә тиеш. Шушы вакыттан күрсәтелгән объектларга салымга ташлама кулланыла башлый.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәренең Олы Мишә авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Карарның 1 пунктында күрсәтелгән 3.2 пункты рәсми бастырып чыгарганнан соң бер ай үткәч көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлдәге хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы Г.А.Маннапов